Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Новозареченск" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында
11 номерлы ХӘБӘР ИТҮ

Баулы муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 3 февралендә 23 номерлы әлеге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының "Новозареченск авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр итәбез.

Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру тәртибе һәм сроклары: Боерык проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар 2025 елның 11 февраленнән 24 февраленә кадәр уздырыла.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар даирәсе: Проект буенча иҗтимагый фикер алышуларда әлеге проектлар әзерләнгән территориядә даими яшәүче гражданнар, әлеге территория чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре катнаша.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар идентификацияләү максатларында үзләре турында белешмәләр бирәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү урынының адресы (регистрация адресы) – физик затлар өчен: атамасы, төп регистрация номеры, урнашкан урыны – юридик затлар өчен, мондый белешмәләрнераслый торган документлар белән. Тиешле җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының яисә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булып торучы биналарның хокук ияләре булган иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар, шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары турында ЕГРНнан (күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан) белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булып торучы урыннарга аларның хокукларын билгеләүче яисә таныклаучы башка документлар тапшыралар.

Иҗтимагый фикер алышулар уздыру территориясе: Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Новозареченск авыл җирлеге бинасында Татарстан Республикасы Новозареческ авылы, Вахитов урамы, 15 йорт.

- Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;
- Измайлово авылы, Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада;
- Дмитриевка авылы, Чапаев урамы, 14а адресы буенча урнашкан бинада;
- Таллыкүль авылы, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада.

Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында;

- Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;
- Измайлово авылы, Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада;
- Дмитриевка авылы, Чапаев урамы, 14а адресы буенча урнашкан бинада;

- Таллыкүль авылы, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада.

Проект экспозициясенең уздыру сроклары: 2025 елның 11 февраленнән 24 февраленә кадәр.

Экспозицияне (экспозицияләрне) карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы: иҗтимагый фикер алышуда каралачак проектны, 2025 елның 11 февраленнән 24 февраленә кадәр, Баулы муниципаль районы рәсми сайтында www.Bavly.tatarstan.ru. «Интернет» челтәрендә, тематик бүлекләр, халык өчен мәгълүмат вкладкасында бастырып чыгарган чорда, идентификация узган иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт аша;

2) язма рәвештә иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты», тел. (85569) 6 07 19;

3) «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналына язу юлы белән.

Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә әлеге проект урнаштырылачак һәм аңа мәгълүмати материаллар кулланып җәмәгать фикер алышулары үткәреләчәк мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, һәм аңа мәгълүмати материаллар: Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәр итүне бастырып чыгарырга: 2025 елның 11 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында www.Bavly.tatarstan.ru «Интернет» челтәрендә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров